**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 декабрь № 1090

г. Казань

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу мониторингы турында

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль законның 97 статьясындагы 8 өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен (карарга теркәлә) расларга.
2. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1090.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 декабрь, 1090 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен
сатып алулар мониторингын гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу мониторингын (алга таба тиешенчә – Федераль закон, мониторинг) гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Мониторинг Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан тәэмин ителә.

4. Мониторинг үткәрү кысаларында түбәндәгеләрне анализлау гамәлгә ашырыла:

контрактның башлангыч (максималь) бәясе 50 млн.сумнан артык булган Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны;

Дәүләт комитеты карары буенча башка сатып алуларны.

5. Мониторинг түбәндәге мәгълүматны җыю, гомумиләштерү, системалаштыру һәм бәяләү юлы белән даими нигездә гамәлгә ашырыла:

сатып алуларны гамәлгә ашыру турында, шул исәптән сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында (алга таба – бердәм мәгълүмат системасы) булган сатып алулар планнарын һәм сатып алулар план-графикларын тормышка ашыру хакында;

Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, оешмалардан, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләрдән, юридик затлар берләшмәләреннән, гражданнардан килә торган хатларда һәм мөрәҗәгатьләрдә булган, шул исәптән дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләрен үтәүгә иҗтимагый контроль нәтиҗәләрен кертеп;

сатып алуларны гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы законлы көченә кергән суд актлары хакында;

башка ачык чыганакларда булган.

6. Мониторинг һәр квартал йомгаклары буенча һәм һәр календарь ел йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла.

7. Дәүләт комитеты, мониторингны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, эксперт оешмалары, иҗтимагый берләшмәләр һәм юридик затлар берләшмәләре, шулай ук башка органнар һәм оешмалар вәкилләре арасыннан эшче төркемнәр формалаштырырга хокуклы.

8. Мониторингны гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне бәяләү үткәрелә:

Федераль законның 13 статьясы нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру максатларына ирешү дәрәҗәсен;

Федераль законның 18 статьясы нигезендә сатып алуларның нигезләнгән булуын;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү зарурлыгын;

Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә һәм раслана торган методика нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү нәтиҗәлелеген.

9. Мониторингны гамәлгә ашыру максатларында, Дәүләт комитеты Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турындагы түбәндәге мәгълүматтан файдалана:

а) сатып алулар планнарын һәм сатып алулар план-графикларын тормышка ашыру хакында, шул исәптән түбәндәгеләр турында:

сатып алуларны гамәлгә ашыру хакындагы урнаштырылган хәбәрнамәләр саны, әлеге хәбәрнамәләрдә булган контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең, бердәнбер кайтартучы (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактлар бәяләренең кушылган мәгънәсе турында, шул исәптән финанслау чыганаклары, кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысуллары, бердәнбер кайтартучы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзү өчен нигезләр, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү буенча башкарылган процедуралар саны, әлеге процедураларны уздыру турындагы хәбәрнамәләрдә күрсәтелгән контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең кушылган мәгънәсе хакында, шул исәптән финанслау чыганаклары, кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысуллары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

контракт төзүгә китермәгән, башкарылмаган дип танылган кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедуралары саны һәм сатып алуларны гамәлгә ашыру турындагы хәбәрнамәләрдә булган контрактларның башлангыч (максималь) бәяләренең, бердәнбер кайтартучы (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактлар бәяләренең кушылган мәгънәсе хакында, шул исәптән финанслау чыганаклары, кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысуллары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

б) контрактлар реестрын алып бару турында, шул исәптән түбәндәгеләр хакында:

Федераль закон нигезендә башкарылган кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедуралары нәтиҗәләре буенча заказчылар төзегән контрактларның саны һәм гомуми кыйммәте, шул исәптән финанслау чыганаклары, кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү ысуллары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

Федераль закон нигезендә бердәнбер кайтартучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) сатып алу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен заказчылар төзегән контрактларның саны һәм гомуми кыйммәте, шул исәптән башкарылмаган кайтартучыны (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедуралары нәтиҗәләре буенча һәм финанслау чыганаклары, бердәнбер кайтартучы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзү өчен нигезләр, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән һәм Федераль закон нигезендә өзелгән контрактларның саны һәм гомуми кыйммәте, шул исәптән Федераль закон нигезендә контрактны төзү өчен нигезләр, финанслау чыганаклары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактларны үтәү, шул исәптән контрактлар өчен түләү турында, контрактта каралган бурычларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгәнгә бәйле неустойкалар (штрафлар, пенялар) исәпләнү хакында, шул исәптән финанслау чыганаклары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт программалары чаралары буенча бүлеп;

в) намуссыз кайтартучылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрын алып бару турында, шул исәптән намуссыз кайтартучылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрына кертелгән сатып алуда катнашучылар саны хакында, шулай кертү өчен Федераль закон нигезендә билгеләнгән нигезләр буенча бүлеп;

г) шикаятьләр, план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрын алып бару турында, шул исәптән түбәндәгеләр хакында:

Федераль закон таләпләре нигезендә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда заказчының, вәкаләтле органның, вәкаләтле учреждениенең, махсуслаштырылган оешманың, сатып алуларны гамәлгә ашыру комиссиясенең, аның әгъзаларының, контракт хезмәте вазыйфаи затының, контракт идарәчесенең, электрон мәйданчык операторының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр саны һәм аларны сатып алулар өлкәсендә контроль органнары тарафыннан карап тикшерү нәтиҗәләре;

Федераль закон нигезендә билгеләнгән контроль объектларына мөнәсәбәтле үткәрелгән план буенча һәм планнан тыш тикшерүләр саны һәм нәтиҗәләре;

заказчы, вәкаләтле орган, вәкаләтле учреждение, махсуслаштырылган оешма, электрон мәйданчык операторы яки сатып алуларны гамәлгә ашыру комиссиясе тарафыннан сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм норматив хокукый актларны бозуны бетерү турында,

шул исәптән кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне бетерү хакында бирелгән күрсәтмәләр саны;

д) банк гарантияләре реестрын алып бару турында, шул исәптән түбәндәгеләр хакында:

әлеге реестрга кертелгән банк гарантияләре саны һәм банк гарантияләрендә күрсәтелгән гомуми акча суммасы;

заказчылар кабул итмәгән банк гарантияләре саны һәм гомуми суммасы, заказчыларның банк гарантиясен алудан баш тартуы өчен Федераль закон нигезендә билгеләнгән сәбәпләр буенча бүлеп;

заказчылар банкларга кайтарган банк гарантияләре саны һәм заказчы банкка җибәрә торган банк гарантияләре йөкләмәләреннән азат ителү турындагы хәбәрнамәләр саны хакында, мондый кайтарылган банк гарантияләренең гомуми акча суммасын яисә әлеге хәбәрнамәләр җибәрелгән банк гарантияләрен күрсәтеп;

е) Федераль законның статьясындагы 5 һәм 6 өлешләр нигезендә контроль гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында, шул исәптән бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган контрольдә тотыла торган мәгълүматның туры килмәвен ачыклау очраклары саны хакында.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр формалаштырыла:

әлеге Тәртипнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән системалаштырылган мәгълүматны үз эченә алган квартал аналитик хисаплары;

әлеге Тәртипнең 11 нче пунктында системалаштырылган мәгълүматны, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү нәтиҗәлелеген бәяләүне, кирәк булган очракта дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү чараларын үз эченә алган җыелма аналитик хисап.

11. Җыелма аналитик хисап түбәндәгеләр турында мәгълүматны үз эченә ала:

сатып алуларны планлаштыру;

сатып алуларны гамәлгә ашыру;

сатып алулар өлкәсендә контрольдә тоту нәтиҗәләре;

Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү нәтиҗәлелеген бәяләү, шул исәптән Федераль законның 13 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алуларны гамәлгә ашыру максатларына туры килү дәрәҗәсен бәяләү хакында, шулай ук Федераль законның 18 статьясы нигезендә сатып алуларның нигезләнгән булуын бәяләү турында;

кирәк булган очракта дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү чаралары хакында.

12. Җыелма аналитик хисап календарь ел йомгаклары буенча әзерләнә.

13. Җыелма аналитик хисапны әзерләү үз эченә түбәндәгеләрне ала:

әлеге Тәртип нигезендә мәгълүматны җыю, гомумиләштерү, системалаштыру һәм бәяләүне;

хисап елының 1 февраленә кадәр җыелма аналитик хисапның бүлекләр, бүлекчәләр һәм кушымталар исемнәрен үз эченә алган структурасын эшләүне;

җыелма аналитик хисапны эшләүне һәм хисап елыннан соң килә торган елның 31 мартына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне.

14. Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында квартал аналитик хисапларын урнаштыру – хисап кварталыннан соң килә торган айның соңгы көненә кадәр (хисап елының соңгы кварталы өчен – хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр), җыелма аналитик хисапны урнаштыру хисап елыннан соң килә торган елның 15 апреленә кадәр гамәлгә ашырыла.

______________________________